Нәҗип Асанбаев -танылган драматург

(Класстан тыш уку дәресе)

Ергизова И.Ф.,
Бүздәк районы Әмир төп белем бирү мәктәбе

Дәрес темасы: **Нәҗип Асанбаев -танылган драматург.**

Максат:

укучыларны Башкортстанда туып-үскән язучылар иҗаты белән киңрәк таныштыру; Нәҗип Асанбаев иҗаты турында өстәмә мәгълүматлар бирү, әсәрләренә анализ ясау, иҗатындагы төп темаларны билгеләү;

укучыларның сөйләм телен үстерү һәм сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү; язучы үрнәгендә укучыларда туган якка, туган як табигатенә мәхәббәт, хөрмәт хисләре тәрбияләү.

Җиһазлау: Н.Асанбаев портреты, китаплары, презентация.

Дәрес барышы.

1.Оештыру.Уңай психологик халәт тудыру.

Хәерле көн, укучылар! Менә тагын яңа көн туды.Яңа көн тууга, безнең бу җирдә яшәүгә ышанычыбыз арта.Туган якның матурлыгын күреп, якыннарыбызның, әти-әниләребезнең яхшы мөнәсәбәтләрен тою үзе бер бәхет икәнлеген аңлап, сөенеч-шатлыклар белән яңа иҗат дәресебезне башлыйбыз.

Бүгенге класстан тыш уку дәресе Башкортстанда туып-үскән, иҗат иткән язучы, драматург Нәҗип Асанбаев иҗатына багышлана. Дәрес телдән журнал формасында үтәчәк.

-Укучылар, Нәҗип Асанбаев нинди авылда туып үскән? Аның турында ниләр беләсез?

Укучы.Нәҗиб Асанбаев 1921 нче елның 7 ноябрендә Бакалы районы Ахман авылында урта хәлле гаиләдә туган. 1921 ел... Ил алдына куркыныч каза ябырылган ел, ачлыктан миллионлаган кешеләр кырылган ел. Шулай итеп, дөньяга килү белән Нәҗип Асанбаевка табигатьнең шәфкатьсез сынавын үтәргә язган була. Әти-әнисе белемле була, рус һәм гарәп графикасын яхшы беләләр. Ахман авылында – башлангыч,

Балыклы җидееллык мәктәбендә белем ала. Авылның бик тырыш игенчесе Василий, ягъни булачак драматургның әтисе, НЭП чорында шактый тернәкләнеп ала, күңелле генә яши башлый. Ләкин бу вакыт матур бер төш кебек кала. Хәлле тормышлы, булдыклы игенчеләрне, шул исәптән Василий агайны да, кулак дигән мөһер басалар да, ашлык иккән басуыннан аерып, башларын җәһәннәмгә олактыралар. Бу гарәфәтнең җиле Нәҗипкә дә килеп кагыла: аны мәктәптән куып кайтаралар.

Укучы. Җиде сыйныф белем алган чәмле үсмер Нәҗип 17 яшендә арытабан да укуын дәвам итәр өчен җәяүләп Уфага юллана.”Уку энә белән кое казу” дигәннәр борынгылар. Моны аңлаган чос егет зирәклеге аркасында 1939 нчы елда Уфа финанс-экономик техникумын тәмамлый һәм Башкорт дәүләт педагогия институтына укырга керә. Ләкин бераздан, әнисенең һәм туганнарының авыр гаилә хәлен күреп Ярмәкәй урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыта башлый һәм читтән торып укуга күчә.

Укучы. Н.Асанбаевка озак эшләргә дә, укуын тәмамларга да насыйп булмый-1940 нчы елда Совет Армиясе сафларына алына. 1941 нче елның декабрендә кече лейтенант хәрби званиесына ия булган асанбаев утлы яу эчендә хәрәкәт итүче армия сафына барып кушыла һәм Воронеж, Калинин, Брянск, 1 нче Балтыйк буе фронтларындагы немец-фашист илбасарларына каршы аяусыз сугыша.Ул артеллерия взводына һәм 76 миллиметрлы пушкалар батареясенә командалык итә.

Укучы. Күптән көткән җиңүне Нәҗип Асанбаев Латвия җирендә Елгава шәһәрендә каршылый. Аның батыр күкрәгендә ике “Кызыл Йолдыз”, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗәдәге Ватан сугышы орденнары, “Батырлык өчен” һәм башка медальләр балкый. Сугыш тәмамлана, ләкин яугир Асанбаевны һаман тыныч тормышка кайтармыйлар, һәм ул 1949 нчы елның декабренә кадәр Совет армиясендә хезмәт итә, югары артиллерия мәктәбен тәмамлый.Шуннан соң гына Нәҗмп Асанбаев Башкортстан Язучылар берлегенең махсус юллавы буенча демобилизацияләнә һәм туган иленә бөтенләйгә әйләнеп кайта.

-Нәҗип Асанбаев иҗатка ничек килә?

Укучы. Исеме 1939-1940 нчы елларда ук әле башкорт әдәбиятында һәм журналистикасында күренә башлаган Нәҗип Асанбаев республиканың “Кызыл таң” гәзитендә эшли башлый. Бу мөхиттә яшәү Асанбаевны җанлы тормышка гына түгел, актив иҗатка якынайта.Ул бик күп танылган

нефьтчеләр, төзүчеләр, сәнагатьнең башка тармакларында эшләүче белгечләр арасында үзенең булачак геройларын таба. Нәтиҗәдә яшь авторның бик күп очерклары, хикәяләре дөньяга туа.

- Нинди өлкәдә танылу таба Н.Асанбаев?

Укучы. Н.Асанбаев Башкортстан республикасының иң күренекле драматургларының берсе булып таныла. Аның әсәрләреннән башка бер театрны да күз алдына китереп булмый. Оста драматургның берсеннән-берсе үзенчәлеклерәк драмалары, берсеннән - берсе көлкелерәк комедияләре буенча куелган чагу спектакльләрне күреп кемнәр генә тетрәнмәгән дә, кемнәр генә сыны катып көлмәгән!

Укучы. Драматургның төрле дәверләрне, заманыбызның колоритлы геройларын чагылдырган һәм аларның язмышларын тирән психологик һәм реалистик чаралар белән сурәтләнгән күп пьесалары театр сәхнәләрен бизәде. Алар арасында “Кәләш әйттергәндә”, “Күктән төшкән бәхет”, “Кеше бәхете”, “Алтын бишек”, “Таң йолдызы”, “Су юлы”, “Зәйтүнгөл”, “Өзелгән өмет”, “Кызлы йорт” һ.б. бар.

-Нәҗип Асанбаевның үз исеме турында ниләр белдегез?

Укучы. Нәҗип Асанбаев - керәшен татары. Аның чын исеме - Николай Васильевич Асанбаев. Әдәби иҗат белән ныклап шөгыльләнә башлагач, ул үзенә Нәҗип Асанбаев дигән исемне ала.

Укытучы. Нәҗип Асанбаевның драма әсәрләре үзе кебек бәхетле булды.Күбесе Башкортстанда гына түгел, бәлки Казан, Ташкент, Ырынбур, Әлмәт, Минзәлә һәм башка театрларда да куелды һәм зур уңыш белән барды.Шулар арасыннан “Рәйсә”, “Ак сиреньнәр”, “Кызыл паша” спектакльләре белән Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт академия драма театры башкалабыз Мәскәүдә җаваплы гастрольләрдә булып, андагы тамашачыларның олы мәхәббәтен яулады.

Һәр язучының газап белән туган әсәрләре була, диләр. Н.Асанбаевның “Кызыл паша”сы әнә шулай, күпме уйланулар, икеләнүләр, эзләнүләр аша дөньяга килә.Авторның тырышлыгы тиккә булмый, бу әсәр аңа зур уңыш һәм казанышлар китерә.Нәтиҗәдә “Кызыл паша” пьесасы буенча эшләнгән фильм-фестиваль башкорт драматургиясен бөтен дөнья аренасына алып чыга. Шушы спектакль белән Башкорт Дәүләт академия театры Бөтен Гарәп илләре театрларының Сирия Мәркәзе Дамаскта үткәрелгән фестивалендә бик уңышлы чыгыш

ясый.Соңыннан “Кызыл паша” спектакле буенча эшләнгән фильм спектакльне 20 дән артык Гарәп илләре сатып ала.

Кыскасы, йомгак ясап шуны әйтеп була: Нәҗип Асанбаевның драматургик иҗаты ифрат бай һәм жанрлар төрлелеге белән аерылып тора. Аның геройлары - тормыш үзе тудырган, төрле авыр сынаулар һәм ситуацияләр аша максатларына омтылган ярсу йөрәкле кешеләр, алар сөяләр һәм нәфрәтләнәләр, төрле киртәләр аша үтәләр һәм соңгы чиктә әхдакый яктан тазарып, сафланып үз юлларыннан баралар.

Нәҗип Асанбаев - бәхетле язмышлы драматург. Ул гомере буена драматургиягә тугрылыклы калды. Аның пьесалары бүген дә төрле сәхнәләрдә куелып тора. Нәҗип абый яшьнәп яшәгән, янып иҗат иткән кеше. Күңел байлыгы, кешеләргә ярдәм итә алуы белән бәхетле яшәгән шәхес.

Дәресебез ахырына якынлаша. Дәрестә актив катнаштыгыз. Киләчәктә дә без якташ язучыларның тормышын, иҗатын өйрәнүне дәвам итәрбез.